ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 036 от «_14» _03_____ 2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы территориясендә табигый һәм техноген
характердагы гадәттән тыш хәлләрдә
эвакуация чараларын планлаштыру һәм
үткәрү буенча эшне оештыру турында
нигезләмәне раслау хакында

«Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияләрне саклау турында» 1994 ел, 21 декабрь, 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Минстрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында” 2018 ел, 5 февраль, 58 нче санлы карары нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне расларга.

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы эвакуация органнарына (эвакуация комиссияләренә) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта әлеге карар белән расланган Нигезләмә нигезендә чаралар планлаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов